ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында” 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8; 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

“$3^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясе субъектларына хезмәт ресурсларын җәлеп итү өстенлекле булып торган Россия Федерациясе субъектлары исемлегенә (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлек) кертелмәгән Россия Федерациясе субъектларының хезмәт ресурсларын җәлеп итү өчен шартлар тудыруны күздә тота торган республика хезмәт ресурслары мобильлеген арттыру программасын (алга таба – республика программасы) әзерләргә, расларга һәм гамәлгә ашырырга хокуклы. Республика программасы Татарстан Республикасында инвестиция проектларын һәм күрсәтелгән программада катнашу турында эш бирүчеләр белән төзелгән килешүләрне гамәлгә ашыруны исәпкә алып әзерләнә. Республика программасында катнашу хакындагы килешүгә кертү өчен мәҗбүри шартлар, эш бирүчеләрнең күрсәтелгән программада катнашу тәртибе “Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында” 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән билгеләнә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәгеләрне билгели:

1) республика программасына кертелергә тиешле инвестиция проектларын сайлап алу тәртибен һәм критерийларын;

2) республика программасында катнашу турында эш бирүче белән төзелә торган килешүгә кертү шартларын, шул исәптән эшкә урнаштыру өчен җәлеп ителгән гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының яңа урында урнашуына бәйле шартларны;

3) эш бирүченең республика программасында катнашуын раслый торган һәм аңа финанс ярдәме алу хокукын бирә торган сертификат (алга таба – сертификат) алуга хокуклы эш бирүчеләрне сайлап алу тәртибен һәм критерийларын;

4) эш бирүчеләргә сертификатта каралган финанс ярдәмен күрсәтү тәртибен;

5) сертификатны кире кайтару тәртибен.”;

2) 4 өлешнең 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“эш бирүчеләргә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлеккә кертелмәгән Россия Федерациясе субъектларының хезмәт ресурсларын җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү;”;

3) 5 өлештә “гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органнары” сүзләрен “гамәлгә ашыру функцияләрен башкаручы органы” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 8 мае
№ 35-ТРЗ